РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ БОЛЬШЕШИНАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422054, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Большой Шинар, ул. Кооперативная, 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422054, Татарстан Республикасы, Саба районы, Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт

тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.04.2021 №10

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 2019 елның 02нче июлендә 11нче номерлы карары белән расланганТатарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге биләмәсендә гражданнардан сораштыру уздыруны билгеләү һәм уздыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” №131-ФЗ Федераль Законына туры китереп Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. 1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 02.07.2019 елда 11нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә гражданнардан сораштыру уздыруны билгеләү һәм уздыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә.

1.1 17.1 пунктының 2 абзацына түбәндәге эчтәлекле сүзләр естәргә: «яки муниципаль берәмлек биләмәсендә яшәүчеләрне»;

1.2 5.7.пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Гражданнардан сораштыруны билгеләү турында карар җирлек Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайты файдаланылырга мөмкин. Авыл җирлеге Советының гражданнардан сораштыруны билгеләү турында норматив хокукый актында билгеләнә:

1) сораштыру үткәрү датасы һәм сроклары;

2) сораштырулар үткәргәндә тәкъдим ителә торган сораштыру формулировкасы;

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазе формасы;

5) сораштыруда катнашучы муниципаль берәмлек халкының минималь саны;

6) «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып, гражданнар арасында сораштыру уздырган очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/shinar адресы буенча бастырып чыгарырга.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Гарипов